# Милләт һәм сәяси аң

Милләт үзенең кемлеген белмәсә һәм кая барганлыгын аңламаса, милләт буларак яшәүдән туктый, мәгънәсез һәм максатсыз халык төркеменә әйләнеп кала. Шуңа күрә һәр халыкның зыялылары һәм сәясәтчеләре милли үзаңны булдыру һәм саклау өстендә даими эш алып баралар. Милли үзаңны үстерүдә тарих, халык бәхете өчен көрәшкән каһарманнар, милли мәдәният зур роль уйный, шушылар аша милләт үзенең кемлеген таный башлый, анда үз-үзенә карата хөрмәт һәм горурлык хисләре уяна. Әмма милли үзаңны уяту ул әле эшнең башы гына, үзенең кемлеген аңлаган милләт каршына зур һәм дөрес максатлар да куя белергә кирәк. Татар халкы кебек дәүләтен җуйган милләт өчен мондый зур максат булып бары тик дәүләт бәйсезлеген торгызу гына тора ала. Татар халкын бары тик шушы зур максат өчен көрәш кенә берләштерә алачак һәм саклап калачак. Чөнки үз дәүләте булмаган, үз милли һәм дини кануннары буенча яшәмәгән халык башка милләтнең тәртип һәм кануннары буенча яшәргә мәҗбүр булачак. Бүген без моны татар халкы мисалында ачык күрәбез, чөнки урыс-христиан дәүләте булган Россиядә татарның теленә дә, диненә дә урын юк. Татар халкының яртысы урыс белән катнаш гаиләләрдә торганлыгын, чиреге урыс кебек эчкече һәм наркоман булганлыгын да әйтсәк, милләтебезнең киләчәге бик фаҗигале күренә. Әгәр милләт үзенең урыс арасындагы чын хәлен һаман аңламый икән, үзенең бетүгә таба барганлыгын сизенеп, ашыгыч чаралар күрми икән, аны татар буларак юкка чыгу көтә.

Бүгенге глобальләштерү һәм милләтләрне юкка чыгару заманында һәр халыкның зыялылары, милли сәясәтчеләре аеруча уяу булырга тиешләр. Чөнки дөньяда барган бу катлаулы процесслар гади халыкка барып җитмәскә дә мөмкин, ә милли элита моны яхшы аңларга тиеш. Ул гына да түгел, милли зыялылар халыкка бу сәяси хәлләрне вакытында дөрес аңлатып, милләткә дөрес юнәлеш бирергә тиешләр. Ягъни, алар милләттә сәяси аңны тәрбияләрә һәм үстерергә тиешләр. Сәяси яктан аңлы булган милләт кенә бүгенге глобаль үзгәрешләрдән, алданулардан, юкка чыгудан исән калырга мөмкин. Милли үзаң милләтнең нигезе булса, сәяси үзаң аның түбәсе булып тора.

Кызганычка каршы, татар халкында сәяси үзаң юк дәрәҗәсендә, бу юнәлештә эшләүчеләр дә күренми. Без тарихка һәм милли мәдәнияткә таянып, халкыбызының милли үзаңын бераз кузгата, уята алдык, Әмма аны сәяси аң дәрәҗәсенә күтәрә алмадык. “Милләт буларак уянгач, нәрсә эшләргә?” – Татар халкы әнә шул сорауга ачык җавап ишетмәде. Милли элитадан татар халкына: “Үз дәүләтең, динең һәм телең өчен көрәш, мөселман-татар булып калу өчен көрәш”, - дигән иң кирәкле сүз әйтелмәде. 450 еллык коллык мәртеннән яңа айный башлаган татар халкына кабат урыс белән дуслык имезлеге каптырылды, толерантность тәресе тактырылды, тынычлык сөюче милләт, дигән наркотик установка бирелде. Әйе, бәйсез дәүләт, дип кенә әйтмә, хак дин тотма, тел сорама, шулай булсаң, шаулатып бәйрәмнәреңне дә үткәрерләр, өеңә килеп, халыкара җыелышлар да уздырырлар, сине “миротворец” үрнәге итеп тә күрсәтерләр... Шулай түбәтәй киеп халыкара мәйданда “Әпипә”гә биеп йөргән арада, тарих тарафыннан татар өчен бирелгән кадерле вакыт үтеп тә китәр... Татар халкыннан музейларга куяр өчен шул чиккән түбәтәй генә торып калыр...

Милли элитаның максатсызлыгы бүгенге көндә татар халкын адашкан сарык көтүенә әйләндерде. Халык кая барасын, нигә барасын, нәрсә эшлисен белми.

Милләтнең үз эчендәге социаль гаделсезлек, иң беренче чиратта, бәйсезлек идеясенә һәм халыкның әхлагына китереп сукты. Кызганчыка каршы, милләт бу елларда халык бәхете өчен көрәшкән милли каһарманлык һәм дини ихласлык үрнәкләрен күрмәде, киресенчә, гади халык та башлыклар  артыннан әхлаксызлык сазлыгына батып бара. Мондый шартларда милләт белән эшләү, аңа дөрес юнәлеш бирү тулысынча милли зыялылар өстенә кала. Татар халкы сәяси яктан үз-үзен сакларлык булып өлгерә аламы, әллә үз эчендәге әхлаксызлыктан, кыйбласызлыктан, тышкы көчләрнең алдау һәм басымыннан тәмам адашып, саташып юлдан таямы – моңа милләтнең зыялылары җавап табарга тиешләр. Милләт шул рәвешле харап була икән, моның өчен татарның бүгенге зыялары да тарих алдында җавап тотарга тиешләр. Чөнки зыялылар җитәкчеләр ялгышканда курыкмыйча аларны төзәтергә, милләт адашканда үрнәк булып аңа дөрес юлны күрсәтергә тиеш иделәр. Ә бүгенге татар зыялыларының бөтен көчләре җан асрауга, мәртәбәле урыннар бүлешүгә, хакимият белән уйнаклауга / заигровать итү/, очсыз-кырыйсыз җыр-бәйрәмнәргә, милләт өчен һич әһәмияте булмаган хезмәтләр тудыруга китә.  Кызганычка каршы, милләттә сәяси аң тәрбияләргә тиешле милли оешмалар да шушы ук бәйрәмчел-показуха сазлыгына кереп баттылар, татар конгрессы да кәгазь лидерларның уле җыеннар оешмасына әйләнде. Югыйсә, татар конгрессының төп эше, миссиясе – татар халкында милли үзаң тәрбияләү, аны сәяси аңлы милләт дәрәҗәсенә күтәрү, татар халкын үзенең милли һәм дәүләти бәйсезлеген торгызуга әзерләү булырга тиеш иде бит! Бу сүзләр, бу идеяләр һәр көн сөйләнеп торырга, һәр җыелыш, һәр корылтай милли һәм дәүләти бәйсезлекне торгызу байрагы астында үтәргә тиеш иде! Татар конгрессы җыеннарында барысы да сөйләнә, әмма милли һәм дәүләти бәйсезлек өчен көрәш темасы гына күтәрелми. Димәк, татар конгрессының да, Татарстан җитәкчеләре кебек, милли мәсьәләдә максатлары юк, алар татар халкының милли һәм дәүләти бәйсезлеге өчен көрәшмиләр.

Бүген бөтен дөньяда татар кебек дәүләтсез халыклар үзбилгеләнү мәсьәләсен күтәрә, ә Татарстан һәм татар конгрессы дәшми. Сербиядән Черногория аерылып чыкты, Испаниядә Католония бәйсезлеккә бер адым ясап, референдум уздырды, алар артыннан баскалар бастырып килә... Хәзер Италиядә, Франциядә шундый ук хәрәкәтләр бара, Англиядә менә инде ничә еллар ирланд халкы үзенең бәйсезлеге өчен кулына корал тотып сугыша. Кавказда Грузия составында булган Көньяк Осетия һәм Абхазия үзләрен бәйсез дәүләтләр дип игълан иттеләр, Россия МИДы бу эшне мөмкин хәл, дип тапты. Молдовиядә Преднестровье урыслары инде ничә еллар аерым яшәп яталар, Кишеневны бар дип тә белмиләр. Инде килеп Кырымда урыслар ни кылана, алар Украина законнарына буйсынмый, хәтта НАТО гаскәрләрен куып җибәрделәр. Сез мондый хәлне Татарстанда күз алдына китерә аласызмы? Югыйсә, Татарстан да 1990 елны үзенеһң дәүләт бәйсезлеген игълан итте бит, 1992 елны бу хакта референдум уздырды! Ягъни, без дә Көньяк Осетия, Абхазия кебек, үзбилгеләндек, димәк, Россия МИДы безнең турыда да, “үзбилгеләнү мөмкин”, дип әйтергә тиеш иде! Әйтмәсә, исенә төшереп, әйттерергә кирәк иде! Татарстан җитәкчеләре бу хакта дәшми, татар конгрессы дәшми, әйтерсең лә, тарихта бәйсезлек турында Декларация дә, референдум да булмаган... Дөрес, без “Иттифак” партиясе исеменнән халыккара оешмаларга бу хакта исләренә төшердек, һәм бу тарихи хакыйкатьне онытырга беркайчан да ирек бирмәячәкбез.  Әмма бу сүзне бүген бөтен татар халыкы белән әйтергә кирәк иде, чөнки вакыты нәкъ шул! Ә бездә Сабантуйлар чоры, зур җыеннар, форумнар вакыты, печән өсте...  Нинди үзбилгеләнү дә нинди дәүләт бәйселеге ди монда бәйрәм белән уттай эш арасында! Ә гади генә итеп әйткәндә, милләттә сәяси аң бик түбән, ул үзенең хокукларын белми, алар өчен көрәшми...

Милләттә сәяси аңның түбәнлеге аның үз язмышына битарафлыгында да ачык күренә. Әгәр татар халкы сәяси яктан аңлы һәм өлгергән булса, ул Татарстанга кытай

эшмәкәрләрен кертеп тутыруга теше-тырнагы белән каршы булыр иде, чөнки бу чирү китәргә дип килми. Без узган тарихыбызда алар белән меңнәрчә еллар көрәш алып барган халык, хәзер инде үз җирләребездә кытай колы булырбызмы? Нигә Алабуга ирекле икътисад зонасын кытай эшмәкәрләренә биргәннәр? Милли элита шул хәтле миңгерәү икән, нигә милли зыялылар дәшми? Нигә тышкы икътисад мәсьәләсендә Татарстан хөкүмәте Кипрның грек ягы белән эш итә, төрек ягына ял итәргә генә бара? Грек белән төрекләр арасында тарихи дошманлык булганын белә торып, нигә без үзебезнең дин һәм кан кардәшләр төрекләрне шулай читкә кагабыз? Әлбәттә, сәяси аң түбән булганга. Шулай ук Татарстан матбугатында әрмән темасын бик күтәреп, бу халыкка мәдхия җырлау сизелә, ә бит алар да төрекләрнең һәм төрки халыкларның тарихи дошманы, Таулы Карабахта бүген дә әрмәниләр төрки-мөселман әзербәйҗаннарга каршы сугыш алып баралар. Сез игътибар итегез – Әрмәнстанда татарлар яшәми, анда бер татар оешмасы юк , ә биредә бөтен авылларны әрмән баскан. Алар да бирегә китәр өчен килми. Болгарда яки Казан кирмәнендә бер әрмән кабер ташы табуны кайберәүләр инде биредә тарихи әрмән җирләре итеп карый башладылар, ә безнекеләр дәшми. Шулай итеп, безнең тарихыбызга да, җирләребезгә дә, үзебезгә дә урыс, кытай, әрмән, юнаннар хуҗа булып бара, ә татар аларга ат кебек эшли, күңелләрен күрер өчен, егылганчы “Әпипә”гә бии...

Сәяси аңы булган милләт иң беренче чиратта үзе турында уйларга тиеш. Башкаларга ирек birә-бирә, татар халкының Тын океаннан Кавказга хәтле җирләре шулай бер карышка калды инде. Хәзер шул бер карышка да башкалар хуҗа булып бара... Без киләчәктә татар милләтенђ нәрсә калдырабыз – нефетебез Мәскәү тарафыннан таланып беткән, җирләребез кытай-әрмән тарафыннан сатып алынган, авылларга әллә кемнәр хуҗа... Тел юк, дин юк, урыс белән катнаш никахлар милләтнең тамырын череткән... Милләт үзенең ни хәлдә калганын аңлап, ашыгыч чаралар күрмәсә, бу гасыр татар өчен соңгысы булырга мөмкин. Шуңа күрә бүген эшләнгән һәр гамәл милләт күзлегеннән чыгып башкарылырга тиеш, ягъни, ул татар халкы өчен файдалы булганда гына тормышка ашырылырга хаклы. Безнең милләт белән мәгънәсез тәҗрибәләр уздырырга хакыбыз да, вакытыбыз да юк, татар халкы өчен исән калуның бер генә юлы бар, ул – үз бәйсез дәүләтен булдыру һәм шунда ислам-әхлак кануннары буенча яшәү. Татарстан җитәкчеләре дә, милли зыялылар һәм сәяәтчеләр дә, татар оешмалары да бары тик шушы максатка гына эшләргђ, халыкта сәяси аң тәрбияләргә һәм татар халкын дәүләт бәйсезлеге өчен көрәшкә әзерләргә тиешләр. Калганы барысы да уен, буш гамәл, мәгънђсезгә үткән гомер һәм нәтиҗәсез эш булачак.

**Фәүзия Бәйрәмова,**
**язучы,**
**“Иттифак” татар милли бәйсезлек партиясе рәисе.**
2006 ел, 19 июнь.